**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «25» маеннан

№ 22-170

«2021 елда «Тарихи хәтер» проектын гамәлгә ашыру һәм
2022 елга бурычлар турында»

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе Г. А.Носованың «2021 елда «Тарихи хәтер» проектын гамәлгә ашыру һәм 2022 елга бурычлар турында» мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе Г.А.Носованың «2021 елда «Тарихи хәтер» проектын гамәлгә ашыру һәм 2022 елга бурычлар турында» мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- Яңа Чишмә муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары исемлеген 2002 елның 1 июненә кадәр актуальләштерергә;
- Яңа Чишмә муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары реестрын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкярләр) Бердәм дәүләт реестрына урнаштыру өчен мәдәни әһәмияткә ия булган объектларны саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына 2002 елның 1 июненә кадәр җибәрергә;
- 2002 елның 31декабренә кадәр Идел буе Болгарының 1100 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрүне оештырырга;
- Яңа Чишмә муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең тарихи истәлекләрне саклау буенча грант эшчәнлегендә катнашуын активлаштырырга;
- Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы тарихы белән бәйле туристик эшчәнлекне популярлаштыру буенча уртак эш алып барырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов